СОВЕТ
ДРОЖЖАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧҮПРӘЛЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** с.Старое Дрожжаное **КАРАР**

2023 елның 5 мае № 28/7

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Советының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясе субъектларында гавами хакимият оештыруның гомуми принциплары турында» 2021 елның 21 декабрендәге 414-ФЗ номерлы Федераль законы, «Татарстан Республикасы Конституциясенә үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 26 гыйнварындагы 1-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы нигезендә Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Советының 2021 елның 26 мартындагы 8/3 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районында муниципаль хезмәткәрләр реестрын алып бару тәртибенең **2.2 пунктына**, «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы» сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәисе) каршындагы» сүзләренә алмаштырып, үзгәреш кертергә.

2. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Советының 2020 елның 3 июнендәге 45/5 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы депутатына, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасына, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затына карата үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында дөрес булмаган яисә тулы булмаган белешмәләр тапшырган өчен, әгәр бу белешмәләрне бозып күрсәтүләр җитди булмаса, җаваплылык чаралары куллану турында карар кабул итү тәртибенең **3 пунктындагы 2 абзацына, 4 пунктына, 5 пунктындагы 2 абзацына, 6 пунктындагы 1 абзацына, 7 пунктындагы 1, 3 абзацларына, 11 пунктындагы 1 абзацына** «Татарстан Республикасы Президентының» сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгының (Рәисенең)» сүзләренә алмаштырып, үзгәреш кертергә.

3. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Советының 2019 елның 23 октябрендәге 38/1 номерлы карары белән расланган Татарстан

Республикасы Чүпрәле муниципаль районында бюджет корылышы һәм бюджет процессы турындагы нигезләмәнең **15 статьясындагы дүртенче абзацына** (2021 елның 27 маендагы 9/4 номерлы, 16.03.2022 № 18/8, 31.05.2022 № 19/4, 13.02.2023 № 25/1 карарлары редакциясендә) «Татарстан Республикасы Президентының» сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгының (Рәисенең)» сүзләренә алмаштырып, үзгәреш кертергә.

4. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Советының 2022 елның 8 августындагы 21/2 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Советы депутаты статусы турындагы нигезләмәнең **18 статьясындагы 1 пунктының б пунктчасына** «Татарстан Республикасы Президентына» сүзләрен «Татарстан Республикасы Башлыгына (Рәисенә) сүзләренә алмаштырып, үзгәреш кертергә.

5. Әлеге карар рәсми басылып чыгарга тиеш.

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль
районы Башлыгы, Татарстан Республикасы
Чүпрәле муниципаль районы Советы Рәисе М.Р. Гафаров